**СОВЕТ ХОЗЕСАНОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ХУҖА ХӘСӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

2019 елның 16 нче сентябре Хуҗа Хәсән авылы №21

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге җирләреннән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы 2009 елдның 2 нче августындагы 283-ФЗ номерлы, «Күп фатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында»гы 2019 нчы елның 27 нче июнендәге 151-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Россия Федерациясендә дәүләт төзелешен күзәтүне гамәлгә ашыру турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында»гы 2009 нчы елның 18нче июлендәге 926 нчы номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карары белән Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Советының 2014 елның 26 сентябрендәге «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләрен раслау хакында»гы 28 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

15 нче мәддәнең 1 нче пунктын 1.1.бүлеге белән тулыландырырга:

«1.1. Җир кишәрлекләре хуҗалары капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешенең,үзгәртеп коруның чик параметрларынан тайпылуга

рөхсәт сорап мөрәҗәгать итәргә хокуклы, әгәр мондый тайпылу рөхсәт ителгән капиталь төзелеш объектларының бер яки берничә чик параметрларын бер тапкыр үзгәртү, конкрет территориаль зона өчен шәһәр төзелеше Регламентында билгеләнгән капиталь төзелеш объектларын төзекләндерү максатларында, ун проценттан артмаган очракта» 27 статьяның 5 пунктындагы 3,4 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) инженерлык эзләнүләр нәтиҗәләре һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше Кодексының 48 мәддәсеннән 15 бүлеге нигезендә расланган проект документациясенең түбәндәге материаллары:

а) аңлатма;

б) җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планында күрсәтелгән мәгълүмат нигезендә башкарылган җир кишәрлеген планлаштыру схемасы, ә линия объектларына карата проект документациясе әзерләнгән очракта, территорияне планлаштыру проекты нигезендә башкарылган бүлеп бирү полосасы проекты (линияле объектны төзү, реконструкцияләү өчен территорияне планлаштыру документларын әзерләү таләп ителми торган очраклардан тыш );

в) архитектура һәм конструктив карарлар булган бүлекләр, шулай ук инвалидларның капиталь төзелеш объектына керә алуын тәэмин итүгә юнәлдерелгән карарлар һәм чаралар (сәламәтлек саклау, мәгариф,мәдәният,ял,спорт һәм социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге башка объектларга, транспорт, сәүдә, җәмәгать туклануы объектларына, эшлекле, административ, финанс, дини билгеләнештәге объектларга, торак фонды объектларына карата проект документларын әзерләү очрагында);

г) капиталь төзелеш объектын төзүне оештыру проекты ( башка капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү өчен аларның өлешләрен сүтү кирәк булган очракта, капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен сүтү эшләрен оештыру проектын да кертеп);

4) капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору, шул исәптән әлеге проект документларында, линияле объектларны да кертеп, капиталь төзелешнең бүтән объектларын төзү яки реконструкцияләү каралган очракта (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше Кодексының 48 мәддәсендәге 12_1 өлешендә каралган, төзелешнең аерым этапларына карата) проект документларына экспертиза үткәрүнең уңай бәяләмәсе, әгәр мондый проект документлары Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 мәддәсе нигезендә экспертизага тиеш булса, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 мәддәсендәге 3_4 өлешендә каралган очракларда Проект документларына дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 мәддәсендәге 6 өлешендә каралган очракларда Проект документларына дәүләт экологик экспертизасының уңай бәяләмәсе;

4.1) Проект документларына кертелә торган үзгәрешләрнең Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 мәддәсендәге 3_8 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау, проект документларын әзерләүне гамәлгә ашыручы затларның әгъзасына нигезләнгән үз-үзен көйләүче оешма әгъзасы булып торучы һәм әлеге зат тарафыннан, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, архитектура-төзелеш проектлаштыруын оештыру буенча белгеч тарафыннан проектның баш инженеры вазыйфасында

килүен раслау, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 мәддәсендәге 3_8 өлеше нигезендә проект документларына үзгәрешләр кертелгән очракта;

4.2) Проект документларына кертелә торган үзгәрешләрнең Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 мәддәсендәге 3_9 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә,башкарма хакимият органы яисә проект документларына экспертиза үткәргән оешма тарафыннан бирелгән таләпләргә туры килүен раслау туры килүен раслау,Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 мәддәсендәге 3_9 өлеше нигезендә эксперт хезмәте барышында проект документларына үзгәрешләр кертелгән очракта;

28 мәдденең 10 пунктындагы 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Дәүләт төзелешен күзәтү предметы булып, капиталь төзелеш объектын төзегәндә, үзгәртеп корганда эшләр башкаруның һәм кулланыла торган төзелеш материалларының туры килү-килмәвен, шулай ук мондый эшләрнең нәтиҗәләрен проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә (энергетика нәтиҗәлелеге таләпләре кагылмый торган капиталь төзелеш объектларыннан кала) һәм капиталь төзелеш объектының кулланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителеше таләпләренә туры килү-килмәвен тикшерү тора.»;

28 мәдденең 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Капиталь төзелеш объектының параметрларын проект документларыннан кире кагу, объектны төзү, үзгәртеп кору, капиталь ремонтлау процессында ачыкланган очракта,бары тик төзүче яисә заказчы тарафыннан яңа расланган проект документлары нигезендә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, аңа тиешле үзгәрешләр керткәннән соң, шул исәптән Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 мәддәсендәге 3_8 һәм 39 өлешләрендә каралган тәртиптә генә рөхсәт ителә.»;

29 мәдденең 3 пунктындагы 9 пунктчасында «проект документлары» сүзләреннән соң «(Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 мәддәсендәге 3_8 һәм 3_9 өлешләре нигезендә кертелгән үзгәрешләр исәпкә алынган проект документациясен да кертеп)» сүзләрен өстәргә.;

32 мәдденең 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Территориаль зоналар чикләре һәр җир участогының таләпләренә, җир законнары нигезендә чикләре территориаль зоналар чикләрен кисәргә мөмкин булган җир кишәрлегеннән тыш, бары тик бер Территориаль зонага гына туры килүе таләпләренә туры килергә тиеш.»

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырырга ;http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникаөия челтәренең рәсми сайтындаурнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Хуҗа Хәсән авыл җирлеге башлыгы Матвеева С.П.